| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Чукмарлинского сельского<br>*поселения Сармановского*<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>*Чукмарлы авыл җирлеге советы* |
| РЕШЕНИЕ<br>2017 ел, 23 март | КАРАР<br>№ 5 |

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы " Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегендә 2007 елның 3 июлендәге 8 номерлы карары белән расланган ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар бирәм::

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Чукмарлы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча ачык тыңлауларны оештыручы - комиссия;

- ачык тыңлаулар үткәрү вакыты-2017 елның 24 апрелендә 14 сәгать;

үткәрү урыны: Татарстан Республикасы, Чукмарлы авылы, Совет урамы, 41 нче йорт, Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитеты;

3. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес: Татарстан Республикасы, Чукмарлы авылы, Совет

урамы , 41 нче йорт, Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитеты (эш көннәрендә 7.00 дән 16.30 сәгатькә кадәр (төшке аш 11.30 дан 13.00 сәгатькә кадәр).

4. Чукмарлы авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия:

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы « Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;;

- ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә 2017 елның 24 апреленнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга;;

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны Сарман муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://sarmanovo.tatarstan.ru/ -.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Чукмарлы авыл җирлеге

Совет Рәисе урынбасары Карпова Г. А